Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Китапханәләр һәм китапханә эше турында"
Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 22 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

"Китапханәләр һәм китапханә эше турында" 1998 елның 21 октябрендәге 1818 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 11; 2001, № 1 – 2; 2004, № 2 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяда:

а) икенче абзацта "тиражланган" сүзен төшереп калдырырга;

б) дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"китапханә фонды – төрле билгеләнештәге һәм статустагы, оештыру ягыннан һәм функциональ яктан үзара бәйле, халыкка китапханә хезмәте күрсәтү максатларында исәпкә алынырга, тупланырга, сакланырга һәм файдаланылырга тиешле документлар җыелмасы;";

в) алтынчы абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

г) җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"документларның мәҗбүри нөсхәсе – җитештерүчеләр тарафыннан тиешле оешмаларга законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм санда түләүсез тапшырылырга тиешле төрле төрдәге документлар нөсхәләре;";

д) сигезенче абзацта "китапханәләр" сүзен "китапханә" сүзенә алмаштырырга;

е) түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

"Татарстан Республикасы милли китапханә фонды – Татарстан Республикасы китапханә фондының аерым тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия булган, даими

саклау һәм иҗтимагый файдалану өчен билгеләнгән һәм Татарстан Республикасы халыкларының мәдәни байлыгы булган өлеше;

китап ядкарьләре – күренекле рухи, матди байлыкка, аерым тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия булган һәм исәпкә алуның, саклауның һәм файдалануның аерым режимы билгеләнгән кульъязма китаплар һәм матбугат басмалары.";

2) 4 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"4 статья. **Китапханәләрнең төп төрләре**

Китапханәләр дәүләт хакимиятенең барлык дәрәҗәдәге органнары, җирле үзидарә органнары, юридик һәм физик затлар тарафыннан гамәлгә куелырга мөмкин.

Гамәлгә куелу тәртибе һәм милек рәвешләре нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган китапханәләрнең түбәндәге төп төрләре аерыла:

1) дәүләт хакимияте органнары тарафыннан гамәлгә куелган дәүләт китапханәләре, шул исәптән:

федераль китапханәләр;

Татарстан Республикасы китапханәләре: Татарстан Республикасы Милли китапханәсе, Республика балалар китапханәсе, Республика яшүсмерләр китапханәсе, Сукырлар өчен республика махсус китапханәсе;

министрлыклар, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең бүтән органнары китапханәләре;

2) җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә куелган муниципаль китапханәләр;

3) Россия фәннәр академиясе, башка академияләр, фәнни-тикшеренү институтлары, мәгариф учреждениеләре китапханәләре;

4) предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар китапханәләре;

5) иҗтимагый берләшмәләр китапханәләре;

6) хосусый китапханәләр;

7) чит ил юридик һәм физик затлары, шулай ук Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләре нигезендә халыкара оешмалар тарафыннан гамәлгә куелган китапханәләр.

Китапханәләрне финанслау, дәрәҗәләренә карап, түбәндәгеләр исәбеннән башкарыла:

федераль бюджет;

Татарстан Республикасы бюджеты;

муниципаль бюджетлар;

иҗтимагый берләшмәләр акчалары;

юридик һәм физик затлар акчалары.";

3) 5 статьяның икенче өлешендә:

а) икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"китапханә хезмәте күрсәтүнең төп төрләрен түләүсез гамәлгә ашыручы гомуми файдаланудагы дәүләт һәм муниципаль китапханәләр челтәрен булдыру;";

б) өченче абзацта "дәүләт" сүзеннән соң "һәм муниципаль" сүзләрен өстәргә;

4) 6 статьяның дүртенче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Хосусый милкендә китап ядкарьләре булган гражданнар, шушы китап ядкарьләрен федераль законнарда каралган тәртиптә теркәгән булса, аларның саклнышын тәэмин итү өчен дәүләттән ярдәм алырга хокуклы.";

5) 7 статьяда:

а) икенче өлешнең икенче абзацында "16 яшькә җитмәгән" сүзләрен "14 яшькә җитмәгән" сүзләренә алмаштырырга;

б) өченче өлештә "Дәүләт китапханәләрендә һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә куелган китапханәләрдә" сүзләрен "Дәүләт һәм муниципаль китапханәләрдә" сүзләренә алмаштырырга;

6) 10 статьяда "Дәүләт китапханәләре, җирле үзидарә органнары китапханәләре" сүзләрен "Дәүләт һәм муниципаль китапханәләр" сүзләренә алмаштырырга;

7) 11 статьяның өченче өлешендә:

а) икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"китапханә фондлары составына керә торган документларны, китап ядкарьләрен, туган якны өйрәнү документларын һәм Татарстан Республикасы дәүләт телләрендәге һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләре телләрендәге документларны да кертеп, федераль законнар нигезендә исәпкә алуны, туплауны, саклауны һәм файдалануны тәэмин итәргә. Китапханәләр фондларына керә торган кульязма документлар Россия Федерациясе Архив фондының состав өлеше була;";

б) өченче абзацны төшереп калдырырга;

8) 12 статьяның беренче өлешендә:

а) дүртенче абзацта "сирәк очрый торган һәм кыйммәтле басмалардан файдаланган өчен" сүзләрен "китап ядкарьләрен, сирәк очрый торган һәм кыйммәтле басмаларны файдалануга биргән өчен" сүзләренә алмаштырырга;

б) унберенче абзацта "мәдәни һәм тарихи ядкарьләр" сүзләрен "китап ядкарьләре рәтенә кертелгән документлардан һәм даими саклау өчен билгеләнгән бүтән документлардан" сүзләренә алмаштырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле яңа уникенче абзац өстәргә:

"китап ядкарьләренең һәм даими саклау өчен билгеләнгән бүтән документларның күчермәләрен алуга, күргәзмәгә куюга һәм алардан файдалануга китапханәләрдән файдалану кагыйдәләре нигезендә чикләүләр билгеләргә;";

г) уникенче абзацны унөченче абзац дип санарга;

9) 13 статьяның өченче өлешендә "хакимияте" сүзеннән соң "һәм җирле үзидарә" сүзләрен өстәргә;

10) 14 статьяның беренче өлешенә түбәндәге эчтәлекле 11 пунктча өстәргә:

"11) Татарстан Республикасы милли китапханә фондын саклауның һәм аннан файдалануның махсус режимын үтәүне тикшереп тору.";

11) 15 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"15 статья. **Татарстан Республикасы милли китапханә фонды**

Татарстан Республикасы милли китапханә фонды документларның мәҗбүри нөсхәсе системасы нигезендә туплана торган документлардан һәм китап ядкарьләреннән тора.

Татарстан Республикасы милли китапханә фонды Татарстан Республикасы күпмилләтле халкының мәдәни байлыгы буларак дәүләт тарафыннан саклана.

Татарстан Республикасы милли китапханә фондына караган документларны исәпкә алу, туплау, саклау, файдалану һәм аларның сакланышын тәэмин итү әлеге Закон, "Документларның мәҗбүри нөсхәсе турында" 1994 елның 29 декабрендәге 77-ФЗ номерлы Федераль закон, "Россия Федерациясендә архив эше турында" 2004 елның 22 октябрендәге 125-ФЗ номерлы Федераль закон, "Россия Федерациясенең Музей фонды һәм Россия Федерациясендә музейлар турында" 1996 елның 26 маендагы 54-ФЗ номерлы Федераль закон, "Татарстан Республикасы документларының мәҗбүри нөсхәсе турында" 2005 елның 18 гыйнварындагы 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, "Татарстан Республикасы Архив фонды һәм архивлар турында" 1996 елның 13 июнендәге 644 номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә китапханәләр, архивлар, музейлар тарафыннан гамәлгә ашырыла.";

12) түбәндәге эчтәлекле $15^1$ статья өстәргә:

"$15^1$ статья. **Китап ядкарьләре**

Китап ядкарьләре милли китапханә фондының аеруча кыйммәтле өлеше була.

Китап ядкарьләре бердәнбер китап ядкарьләренә һәм килеп чыгышлары, төр ягыннан бәйләнешләре йә бүтән билгеләре буенча бергә берләшкәндә генә китап ядкаре үзенчәлегенә ия була торган документлар җыелмасы рәвешендәге коллекция китап ядкарьләренә бүленә.

Китап ядкарьләре китап ядкарьләре реестрында теркәлергә тиеш.

Документларны китап ядкарьләренә кертү тәртибе, китап ядкарьләрен китап ядкарьләре реестрында теркәү тәртибе, китап ядкарьләре реестрын алып бару тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә.";

13) 16 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"16 статья. **Китапханә фондлары составына керә торган документларны исәпкә алу, туплау, саклау һәм алардан файдалану**

Китапханә фондлары составына керә торган документларны исәпкә алу, туплау, саклау һәм алардан файдалану законнар һәм бүтән норматив хокукый актлар нигезендә гамәлгә ашырыла.

Китапханә фондлары составына керә торган документларны исәпкә алуны, туплауны, саклауны һәм алардан файдалануны мәдәният өлкәсендәге федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә китапханәләр тәэмин итә.

Документларны саклау һәм озак вакыт файдалану максатларында Татарстан Республикасында микросаклагычларда, аудиовизуаль чыганакларда, фонодокументларда, матбугат басмаларын һәм кульязмаларны кабатлаучы электрон басмаларда иминият китапханә фондлары төзелә.

Дәүләт китапханәләренең иминият китапханә фондларына мәҗбүри тәртиптә түбәндәгеләр кертелә: нигез салынган көннәреннән алып җирле вакытлы басмалар, китап ядкарьләре.

Гамәлгә куючы китапханә фондларын саклау режимына туры килерлек бина бирергә тиеш.

Китапханәләр, документларның мәҗбүри нөсхәсеннән тыш, документлар сатып алу чыгынакларын ирекле рәвештә сайлый.

Китапханә фондларын туплау түбәндәгечә башкарыла:

законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм санда мәҗбүри нөсхәләр алу нигезендә;

акчалата түләп һәм акчалата түләнми торган исәп-хисап аша сатып алу юлы белән;

китап алмашу рәвешендә;

физик һәм юридик затлардан иганәләр рәвешендә һәм бушлай тапшыру юлы белән.";

14) 18 статьяда:

а) өченче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Муниципаль районның җирле үзидарә органнары җирлекара әйдәүче китапханәгә үзәк район китапханәсе статусын бирә ала.";

б) дүртенче өлештә "оештыралар" сүзеннән соң ", китапханәара абонемент функцияләрен гамәлгә ашыралар, җыелма каталог алып баруны тәэмин итәләр" сүзләрен өстәргә;

15) 21 статьяда:

а) икенче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Татарстан Республикасы милли китапханә фонды, республиканың мәдәни һәм фәнни байлыгы булган документларны киләчәк буыннар өчен саклауны тәэмин итеп, мемориаль әһәмияткә ия була.";

б) бишенче өлешнең икенче абзацында "икешәр" сүзен "өчәр" сүзенә алмаштырырга, "бушлай" сүзен төшереп калдырырга;

16) 24 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"24 статья. **Китапханәләр мөлкәте**

Китапханә оператив идарә итү хокукларында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләрдә үзенә беркетелгән мөлкәтне биләп, аннан файдалана һәм аның белән эш итә.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2010 елның 16 мае
№ 16-ТРЗ